Бәйрәмова-Аймал, Ф. "Кырык сырт" китабы чыкты / Ф. Бәйрәмова-Аймал // Мәдәни җомга. – 2024. – №18 (8 май). – С. 3.

# «Кырык сырт» китабы чыкты

Казанның «Милләт» нәшриятында язучы, тарихчы Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» китабы басылып чыкты. Бу тарихи роман узган гасырның утызынчы елларында Магнитогорскига сөргенгә сөрелгән татарлар турында. Аларны, совет властена каршы эшлиләр, дигән ялган яла белән, туган авылларындагы йорт-җирләреннән куып, Урал арьягындагы буш далага, Магнитканы төзәргә илтеп ташлыйлар. Тоткыннар арасында Мәккә-Мәдинәләрдә, Истанбул-Каһирәләрдә белем алган дин әһелләре, авылның хәлле, баерак кешеләре, укымышлы белем ияләре күп була. Автор Магнитогорскига барып, бу теманы өйрәнде, сөргенгә сөрелгәннәрнең исән калган нәсел дәвамчылары белән очрашты, архивларда эшләде. Аның әйтүенчә, ул чакта Татарстаннан Магниткага йөз меңгә якын татар сөрелгән, алар ишле гаиләләре, әби-бабалары белән авылларыннан куылган. Бу мәхбүсләрнең күпчелеге беренче кышта ук ачтан һәм салкыннан өшеп үлә, бигрәк тә балалар һәм картлар күп кырыла. Фәүзия Бәйрәмова милләтебез башына килгән бу фаҗигане җан тетрәткеч итеп тасвирлаган, вакыйгалар тормышның үзеннән алынган, хәтер күзәнәкләренә кан белән уелып язылган... Шушындый кеше чыдамаслык авыр шартларда да татарлар берләшеп, исән калу юлларын эзли, бер-берләрен ташламый, сөргендә дә татар булып, намазлы мөселман булып кала. Бу китап – милләтебезнең бөеклегенә мәдхия!

Ә ни өчен әсәр «Кырык сырт» дип атала соң? Бу авырлыкларга түзә алмыйча, исән калу өчен, тоткыннарның бер өлеше сөргеннән кача. Ә алда аларны Урал тауларының кеше үтмәслек кырык сырты көтә, шул сыртларда балалары, әби-бабалары үлеп кала, ә туган авылларында аларны, сугым пычаклары тотып, Шайтан Шакирлар көтеп тора... Татар халкы, Казан алынганнан бирле, менә шушы кырык сыртны үтә, бу дөньяда ук сират күперен кичә...

Ф.Бәйрәмованың бу әсәре, 2005 елда, Казанда, Татарстан китап нәшриятында, шушы исемдәге романнар җыентыгында басылып чыккан иде. Китап бик тиз арада таралып бетте, ә халык аны сорады да сорады. Менә шушыларны истә тотып, «Кырык сырт» романын үзен генә аерым китап итеп бастырып чыгарырга уйладык, нәшер Фәния Хуҗахмәт моны тиз арада тормышка да ашырды, аңа Аллаһның рәхмәтләре булсын!

Китап зур булмаган тиражда, үз акчабызга, игелекле кешеләр ярдәме белән дөнья күрде, аларга да Аллаһның рәхмәтләре булсын! Аны Казанда «Милләт» нәшриятының офис-кибетләрендә сатып алырга була.

**Фәүзия БӘЙРӘМОВА-АЙМАЛ.**